ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 280

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«24» июль 2019 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2017 елның 30 октябрендәге 326 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2017 елның 30 октябрендәге 326 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 09 апрелендәге 137 номерлы, 2018 елның 23 июлендәге 275 номерлы, 2019 елның 24 гыйнварындагы 31 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:
1.2 пунктның 7 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;
1.3 пунктның 50 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;
1.4 пунктта «гамәлгә ашыру тәртибенә» сүзләрен «күпфатирлы йортта торак урынны торак булмаган урынга күчерү тәртибенә, гамәлгә ашыру тәртибенә» сүзләренә алмаштырырга;
1.11 пунктның 5 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2 бүлектә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Инспекциянең эш графигы:

дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе – 8.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр;

җомга – 8.30 сәгатьтән 16.15 сәгатькә кадәр;

төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Бәйрәм алды көннәрендә эш көне 1 сәгатькә кыскартыла.

Инспекциянең территориаль органнары турында мәгълүмат шушы Регламентка 1 нче кушымтада урнаштырылган.»;

2.3 пунктның унынчы абзацында «www.gji.tatar.ru» сүзләрен «www.gji.tatarstan.ru» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктның икенче абзацында «www.gji.tatar.ru;» сүзләрен «www.gji.tatarstan.ru;» сүзләренә алмаштырырга;

2.12.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12.2. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга планлы тикшерү билгеләнгән тәртиптә Инспекция тарафыннан эшләнгән һәм расланган юридик затларга, шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр уздыруның еллык планы (алга таба – юридик затларны, шәхси эшкуарларны тикшерүнең еллык планы) нигезендә һәм аңа ярашлы рәвештә уздырыла.

Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр, критерияләргә ярашлы рәвештә алар тарафыннан гамәлгә ашырылучы эшчәнлеккә беркетелгән куркынычлылык категориясенә карап, түбәндәге ешлыкта уздырыла:

югары куркынычлылык категориясе өчен – ике елга бер тапкыр;

шактый куркынычлылык категориясе өчен – өч елга бер тапкыр;

уртача куркынычлылык категориясе өчен – алты елга бер тапкыр һәм сигез елга кимендә бер тапкыр;

куркынычлылыкның түбән категориясе өчен – планлы тикшерүләр үткәрелми.»;

2.13.3 пунктта:

беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәрге чорда үзләре турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы нигезләмәләргә ярашлы нигездә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль законның $26^2$ статьясындагы таләпләргә ярашлы рәвештә оештырыла һәм үткәрелә.»;

2.14 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Инспекциягә, асылда ТКХ ДМС ярдәмендә, гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан мәгълүматлар килү, ТКХ ДМС Инспекциянең түбәндәге фактлар турында мәгълүматны ачыклавы:

а) түбәндәге таләпләрнең бозылуы:

– күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү, туктатып тору һәм чикләү

кагыйдәләре;

– торак милекчеләре ширкәтен, торак, торак-төзелеш яки башка төрле махсуслаштырылган кулланучылар кооперативын төзү тәртибенә, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка төрле махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы уставы;

– торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка төрле махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы уставына үзгәрешләр кертү тәртибе;

– күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан, идарәче оешма белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсен төзү максатларында, күпфатирлы йорт белән идарә итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы (алга таба – идарәче оешма) юридик затны, оешу-хокук формасына бәйсез рәвештә, яки шәхси эшкуарны сайлау турында карар, идарәче оешма белән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) эшләр башкаруга шартнамә төзү турында карар, Россия Федерациясе Торак кодексының 164 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән затлар белән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) ремонтлау буенча эшләр башкаруга шартнамәләр төзү турында карар кабул ителү тәртибе;

– күпфатирлы йортта торак урынны торак булмаган урынга күчерү тәртибе;

– күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибе;

– күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) ремонтлау буенча эшләр башкаруга шартнамәләрнең шартларын раслау тәртибенә, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтен карап тоту һәм әлеге йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау тәртибе;

б) идарәче оешманың Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясының 2 өлешендә каралган бурычларны бозуы;

в) коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар кертә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын куллану өлкәсендәге бозулар;

г) коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллануның билгеләнгән норматив күләменең нигезсез булуы, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативлары составына карата таләпләр бозылуы, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) куллану нормативларын билгеләү шартларын һәм методларын сакламау, күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен бозу;

д) социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннарын наймга тапшыручылар тарафыннан мондый йортларда наймга бирүчеләргә һәм торак урыннарны наймга алучыларга карата, социаль файдаланудагы торак фондына караган торак урыннарының найм шартнамәләрен һәм торак урыннарның найм шартнамәләрен төзүгә карата таләпләрнең бозылуы;»;

2.17 пунктта:

беренче абзацта «зарури таләпләр бозылуы турында яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «, гамәлгә ашырыла торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.18 пунктта «зарури таләпләр бозылуы турында яки» сүзләрен төшереп

калдырырга;

3 бүлектә:

1 нче таблицада «ТР ДТИ компетенциясе чикләрендә капиталь ремонт фондлары төзелүен тикшерүдә тоту» юлының 3 нче графасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«РФ Торак кодексының 170, 170 ст., 52-ТРЗ номерлы Законның 12 ст., ТР Дәүләт торак инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсус коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан белешмәләр тапшыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 30 октябрендәге 431 номерлы боерыгы (алга таба – 431 номерлы боерык)»;

4 бүлектә:

2 нче таблицаның 11 нче һәм 12 нче юлларының 2 нче графасында «151 номерлы ТР ДТИ боерыгы» сүзләрен «431 номерлы Боерык» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче таблицаның 13 нче юлындагы 2 нче графасында «Россия Төзелеш министрлыгының «Торак урынны карап тоту һәм ремонтлау һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү кертү өчен түләү документының үрнәк формасын һәм аны тутыру буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 924/пр номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Төзелеш министрлыгының «Торак урынны карап тоту һәм ремонтлау һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү кертү өчен түләү документының үрнәк формасын раслау турында» 2018 елның 26 гыйнварындагы 43/пр номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.32.1 пункт өстәргә:

«5.32.1. Планлы тикшерү уздырганда Инспекциянең вазыйфаи затлары тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) файдаланырга тиеш.

Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) куллану барлык юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерү барышында гамәлгә ашырыла.

Планлы тикшерү уздырылганда кулланыла торган тикшерү кәгазьләрендә (контроль сораулар исемлекләрендә) юридик затка һәм шәхси эшкуарга белдерелә торган, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә зыян салыну куркынычы барлыкка килүгә, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр куркынычына юл куймау күзлегеннән караганда үтәлеше аеруча әһәмиятле булган зарури таләпләргә кагылышлы сораулар була.

Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерү предметы тикшерү кәгазьләренә кертелгән сораулар исемлеге (контроль сораулар исемлекләре) белән чикләнә.

Тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча тутырылган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) тикшерү актына теркәлә.»;

5.27 пунктның 3 пунктчасында, 5.59 пунктның бишенче абзацында һәм 5.96 пунктның 5 пунктчасында «Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 бүлектә:
7.3 пунктның беренче абзацында «www.gji.tatar.ru» сүзләрен «www.gji.tatarstan.ru» сүзләренә алмаштырырга;
10 нчы кушымтада «23.55 ст. 2 өл. 3 п.» сүзләрен «23.55 ст. 2 өл. 1 п.» сүзләренә алмаштырырга.
2. Юридик бүлек башлыгына (Н.Н. Воронская) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – баш дәүләт торак инспекторы урынбасары – хокук идарәсе башлыгы В.С.Саттаровка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы В.И. Маряшев